**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылында гражданнар җыены карары**

13 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- торак пункт территориясен төзекләндерүгә (Бөек Ватан сугышы һәйкәлен ремонтлау, балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә).

- коймалар коруга, ремонтлауга, традицион җирләү урыннарын төзекләндерүгә (материаллар сатып алуга) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы _________ Р.Н. Шәрәфетдинов

Халык җыены секретаре _________ А.И.Гәләветдинова